

Гомер-гомергә ноябрь аенда каз суя башлыйлар. Дорес, ул чакта бу вакытларда инде әллә кайчан кар тошкән була иде. Хәер, хәзер салкын коннәрне котеп торасы юк, һәр кешедә суыткыч, суйган казны куярга урын бар.
Тагы хәзер омәләр дә юк диярлек, чонки һәрбер кеше vзе генә дә бу эшне башкарып чыга. Ник чыкмаска диген: я vтvкләп, я кипятокка батырып бер минут эчендә каз мамыгын йолкып ташлыйлар. Дорес, дорес – ташлыйлар. Ник дип сорарсыз – каз мамыгыннан ясалган мендәрләр, ястыклар, тvшәкләр хәзер не в моде. Барыбер, калды әле безнен каз мамыгыннан ясалган ястыкларда рәхәтләнеп йоклаучылар!      Ноябрь ае кергәчтен, аз булса да, Мордовия авылларында да каз йолку омәләре vткәрvчеләр булды. Мәсәлән, Ромодан районы Алтар авылында, Кадошкино районы Большие Поляны һәм башка кvп кенә авылларыбызда. Әле декабрьдә каз йолку дәвам иттерелә. Әйтик, Ромодан районы Алтар авыл клубы хезмәткәрләре, милли елаларыбызны киләчәк буынга тапшыру максаты белән, регионыбызда кин колач алган «Шумбрат, Мордовия!» фестиваленде дә каз омәсе кvрненешен «Чишмә» ансамбле башкаруында зур сәхнәдән кvрсәттеләр (фотода). Сvз унаеннан, 25-26 ноябрьдә Татарстаннын Мослим районында II Ботенроссия «Каз омәсе» фестивале узды. Быел фестивальдә катнашырга 400 кеше гариза жибәргән. Киләсе елга да биредә vткәрергә карар кылганнар. Бу чара Россиядә vзен танытып Ботендонья кvләменә чыгачак дигән фикерләр дә булган.
Кvмәк эшләгән эш кvнелле дә, тиз дә. Каз омәсе дә шулай. Кичтән ягылган жылы мунчада хатын-кызлар, кара-каршы утырып, каз йонын йолкый. Элегрәк коры килеш йолкыганнар, аста калган йомшак мамыгыннан киявгә китәчәк кызлар очен мендәр ясаганнар. Хәзер, эшне жинейләтер очен, казнын остен юеш марля аша vтvклиләр, дидем. Ө кайнар суда пешекләп алганнар йонын һәркем vзенчә киптерә. Безнекеләр, юсан рәте китә дип, сеткага салып, тышта жиллэтеп торалар.
Элек һәр йортта берничә ана каз, ата каз асраганнар. Яз житvгә, оя тутырып бәпкә чыгарганнар, бала-чага, әби-чәби шуны жыелышып саклаган. Хәзер инде йорт казлары асрау тарихка гына кереп калды дисән дә була, чонки инкубаторлардан сатып алу ел буе каз асраугa караганда жайлырак.
Каз итен кvбрәк Яна елны каршылыгында пешерәләр, кунак остәлләренә чыгаралар, манты-бәлешләр пешер-гәндә кушып жибәрәләр. Авыл урамнарын, болын-елгаларны тутырып йоргән казларны, шундый омәләрне кvрv кvнелгә рәхәтлек бирә. Ризык очен генә тvгел, әнә шулай кvрше-тирәне, туганнарны берләштерv чарасы булуы, гореф-гадәтләрне янартуы белән дә кадерледер ул.

**Наилә НАСЫРОВА**